ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТУРАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2020 елның 1 апреленнән №15

Турай авыл җирлеге территориясендә
коронавирус йогышын профилактикалау буенча
чаралар планын раслау турында

Россиядә коронавирус эпидемиясе белән бәйле рәвештә

КАРАР БИРӘМ:

1. Турай авыл җирлеге территориясендә кушымта нигезендә коронавирус йогышын профилактикалау буенча чаралар планын раслау турында.
2. Әлеге карарны Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatarstan.ru “Турай авыл җирлеге" бүлегендә бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Турай авыл җирлеге Башлыгы А.М.Рәхимова

Кушымта
Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Турай авыл җирлеге башлыгының
2020 елның 1 апреленнән
15 нче номерлы карарына

**Авыл җирлеге территориясендә**
**коронавирус йогышын профилактикалау буенча чаралар планы**

| № | Чара атамасы | Үтәлеш вакыты | Җаваплы затлар |
|---|---|---|---|
| 1. | Йогыштыру куркынычлары, шәхси профилактика чаралары (мәгълүмат такталары, белешмәләр, игълан) турында халыкка мәгълүмат җиткерү буенча системалы эшне тәэмин итәргә | 01.04.2020 башлап махсус боерыкка кадәр | Авыл җирлеге Башлыгы, учреждение җитәкчеләре, ИП |
| 2. | Кешеләр күпләп җыела торган урыннарда, (шул исәптән сәүдә объектларында), дезинфекция режимын көчәйтү буенча чаралар оештырырга | 01.04.2020 башлап махсус боерыкка кадәр | Авыл җирлеге Башлыгы, учреждение җитәкчеләре, ИП |
| 3. | Яна коронавирус инфекциясе йоктыру куркынычы, шәхси профилактика чаралары һәм кискен респиратор авыруы симптомнары булган очракта, медицина ярдәменә кичекмәстән мөрәҗәгать итү турында халыкка мәгълүмат бирүне тәэмин итәргә | 01.04.2020 башлап махсус боерыкка кадәр | Авыл җирлеге Башлыгы, учреждение җитәкчеләре, ИП |
| 4. | Шәхси һәм иҗтимагый профилактика чаралары турында халык арасында киң санитар-агарту эшен гамәлгә ашырырга. | 01.04.2020 башлап махсус боерыкка кадәр | Авыл җирлеге Башлыгы, учреждение җитәкчеләре, ИП |
| 5. | Җирлек территориясендә массакүләм чараларны тыярга. | 01.04.2020 башлап махсус боерыкка кадәр | Авыл җирлеге Башлыгы, учреждение җитәкчеләре, ИП |
| 6. | Эпидемиягә каршы режимны көчәйтергә, беренче чиратта - административ биналарда җилләтү режимын. | көн саен | Авыл җирлеге Башлыгы, учреждение җитәкчеләре, ИП |
| 7. | Дымлы җыештыру үткәргәндә дезинфекция чараларын куллану. | көн саен | Авыл җирлеге Башлыгы, учреждение җитәкчеләре, ИП |
| 8. | Көчле респиратор авыру билгеләре булган затларны эшкә кертмәскә | даими рәвештә | Авыл җирлеге Башлыгы, |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | учреждение җитәкчеләре, ИП |
| 9. | Җирлек территориясендә агымдагы эпидемиологик вәзгыять турында мониторинг үткәрү | даими рәвештә | Авыл җирлеге Башлыгы |